Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN

УНИВЕРСИТЕТ

№ 2 (15)

26 гыйнвар 2012 ел

## • Ректорат яңалыклары

23 гыйнвар көнне Казан федераль университеты ректоратының Илшат Гафуров җитәкчелегендә чираттагы утырышы узды.

Традиция буенча, беренче булып икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин КФУның Үсеш программасын тормышка ашыру турында чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, 2011 ел нәтиҗәләре югары уку йортының күп индикаторлар буенча алда баруын күрсәтә. Мәсәлән, электрон белем бирү ресурслары (248 гә 60) планлаштырылганнан икеләтә арттырып эшләнгән, аспирантлар саны арткан, өстәмә белем бирү программалары да сан ягыннан шактый зур үсеш кичергән. Узган ел эчендә 25 кече инновацион предприятие (планда каралганнан 14 кә күбрәк) булдырылган. Шулай ук Татарстан Республикасыннан булмаган студентларның, югары уку йортыбызда белем һәм тәрбия бирүче чит ил галимнәренең артуы да күңелле күренеш. КФУ биналарында төзекләндерү эшен алып бару буенча да план арттырып үтәлгән.

«Без яхшы тизлек белән барабыз, ләкин бу, үз чиратында, безнең өскә зур бурычлар йөкли», – дип билгеләп үтте проректор. Моннан тыш, ул хәзерге вакытта «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе»нә дәүләт ярдәме күрсәтү» турында Татарстан Республикасы Законы эшләнүен һәм әлеге проектның килешенү узуын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел планына «Казан (Идел буе) федераль университетының 2012-2019 елларга озак сроклы максатчан үсеш программасын раслау турында» дип аталган проект эшләнмәсе кертелүен дә хәбәр итте. Ректор Илшат Гафуров уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзариповка, фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиевка һәм структур бүлек җитәкчеләренә (Филология һәм сәнгать институты, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты), әлеге проектларга кертү максатыннан, тәкъдимнәр җиткерү турында йөкләмәләр бирде.

Шуннан соң университетның аерым бүлекләренең үсеш программасын тәкъдим итү булды. КФУның Алабуга шәһәрендәге филиалы турында – директор Елена Мерзон, Педагогика һәм психология институты турында директор Айдар Кәлимуллин чыгыш ясады. Докладларга бәйле фикер алышулар барышында, Илшат Гафуров уку йортында Белем бирү буенча координация советы оештырырга тәкъдим итте. «Биредә Казан федераль университетында педагогик белем бирүгә бәйле мәсьәләләр күмәк хәл ителер иде», – диде.

2012 елда абитуриентлар кабул итү турында Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко сөйләде.

Ахырдан Укыту-методик идарә җитәкчесе Ольга Тимофеева бакалавриат һәм магистратура программаларының стандартларын тәкъдим итте.

Ректоратның киләсе утырышында биология һәм туфракны өйрәнү факультетының үсеш программасы каралачак. Моннан тыш, факультет һәм институт җитәкчеләре ректорның хезмәт хакына өстәмә түләвен алачак яшь белгечләрнең исемлеген тәкъдим итәчәк.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# «Сезнең язмыш - сезнең кулларда!»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

1755 елның 25 гыйнварында Императрица Елизавета Петровна Мәскәү университетын ачу турындагы указга кул куя. Баштарак ул университетның туган көне итеп билгеләп үтелсә, алга таба студентлар бәйрәменә әверелә. 2005 елдан башлап бу көн Россиядә студентлар көне буларак уздырыла.

Безнең университетыбызда да Студентлар көне ел саен зурлап бәйрәм ителә. Кичә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов КФУның Актлар залында ТРның аспирантлар, студентлар, югары, урта һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесе укучылары – махсус дәүләт стипендиатлары белән очрашты.

Хөкүмәт башлыгы килгәнче, КФУ ректоры Илшат Гафуров республикабызның төрле уку йортларыннан җыелган дәүләт стипендиатларына КФУ турында видеоролик, Үсеш программасын тәкъдим итте. Яңа ачылган бүлекләр, яңа идеяләр белән таныштырды.

Барлыгы 90 стипендиат арасында 22 аспирант – 33 мең 300 сум, 48 югары уку йорты студенты һәм хәрби училище курсантлары – 27 мең 800 сум, 10 урта махсус белем бирү йорты студенты – 16 мең 700 сум, башлангыч һөнәри белем бирү йортыннан 10 укучы 15 мең күләмендә стипендиягә лаек булды.

Ректор, Президентыбыз һәм залдагы башка дәүләт эшлеклеләрен сәламләп, бөтен студентларны бәйрәм белән котлады. Барлыгы университетта Татьяна исемле 318 студент укый һәм 218 укытучы һәм хезмәткәр эшли икән. Залдагы Татьяналарга Президент чәчәк бәйләмнәре тапшырды. «Бу чарада катнашуыма мин бик шат. Бер-беребезне тыңлау, фикер алышу, булган проблемаларны күрсәтү өчен бик яхшы мөмкинлек. Без бөтен кыенлыкларны да җиңә алабыз, чөнки шундый көчле уку йорты, ныклы нигез, теләк бар. Безне хәзер бөтен җирдә дә беләләр, бу, әлбәттә, сезнең кебек студентлар тырышлыгы», – диде.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Фән дөньясында

# Татьяна Геллер истәлегенә

**Гөлшаһидә ДАУТОВА,**
ifi.kpfu.ru сайты хәбәрчесе

25 гыйнвар көнне университетта «XXI гасырда әдәбият белеме һәм эстетика» дип аталган IX республикакүләм фәнни конференция ачылды. Ул Татьяна Александровна Геллер истәлегенә багышлана.

Татьяна Геллер бөтен гомерен студентларына багышлый. Ул рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасы доценты була, 25 ел дәвамында эстетика буенча түгәрәк алып бара. Бирегә тарихчы, филологлар белән бергә КХТИ, КДУ һәм КАИдан техник белгечләр дә йөри. Студентларны ул матурлыкны күрергә: музыка тыңларга, театрга йөрергә, өстәл янында үзеңне ничек тотарга, кунакка йөрергә, ничек киенергә өйрәтә.

**Ахыры 2нче биттә.**



Энҗе Ибраһимова фотосы

## Ике авыз сүз

19 гыйнвар көнне КФУга Польшаның Лодзин воеводалыгыннан делегация килде. Лодзин воеводалыгы Польша үзәгендә урнашкан. Ул берничә эре шәһәрне берләштерә. Башкаласы – Лодзь шәһәре академик һәм халыкара фәнни хезмәттәшлек үзәге булып тора. Биредә 27 югары уку йорты бар, шуларның 6 сы дәүләт вузы.

Визит барышында, кунаклар КФУ җитәкчелеге, укытучылар белән очрашты. Аларга уку йортының тарихы, бүгенгесе турында мәгълүмат җиткерелде. Казан университеты һәм Польшаның мәгариф учреждениеләре белән хезмәттәшлекне арттыру максатыннан, Россия-Польша фәнни үзәге оештырыла.

Воевода Йоланта Хелминска, үз чиратында, Польшадагы мәгариф системасы, уку йортлары белән таныштырды. Аның сүзләренә караганда, кайбер проектларны тормышка ашыруда үзара хезмәттәшлекне арттыру кирәк булачак.

• • • •

21 гыйнвар көнне Россия һәм Татарстанның вуз ректорлары РФ мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко белән очрашты. Утырышны мәгариф башлыгы үзе алып барды. «Студентларның мөстәкыйльлеге» турында сөйләшүне ул аралашу өчен төп тема итеп билгеләп: «Студентларның активлыгын арттырыр урында, без алар өчен проблемаларны хәл итәбез. Ирек бирергә кирәк», – диде. Югары белем бирүдә ирешелгән уңышлар турында сөйләде. Эш белән тәэмин итүчеләрнең укыту процессында катнашуын һәм югары мәктәпнең кадрлар әзерләүдә алар фикерен исәпкә алуын уңай күренеш буларак билгеләде. Вузларның тикшеренү өлкәсендә нәтиҗәле эшләвен ассызыклады.

Бу көнне РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы белән «Студентлар баскетболы ассоциациясе» арасында килешүгә кул куелды.

• • • •

Төрле дәүләт оешмаларында эшләүче белгечләр мөрәҗәгате буенча Филология һәм сәнгать институтында ТРның Министрлар Кабинеты ярдәме белән татар теле курслары оештырылды. Курслар 3 ай (февраль-апрель айлары) дәвам итәчәк. Укыту коммуникатив методика буенча ике төркемдә алып барылачак: яңа өйрәнә башлаучылар өчен татар теле һәм дәвам итүчеләр өчен татар теле.

Институтта телләр өйрәнү өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган: югары квалификацияле белгечләр эшли, лингвафон кабинетлар, фәнни-методик кулланмалар бар. Курсларны үткәрү һәм катнашу буенча тулырак мәгълүматны Филология һәм сәнгать институтында алырга мөмкин.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

## Татьяна Геллер истәлегенә

**Башы 1нче биттә.**

Һәр каникул саен алар музейларга баралар, Алабуга, Мәскәү, Санкт-Петербург, Псков, Киров кебек тарихи шәһәрләрдә булалар.

Рус филологиясе бүлеге җитәкчесе Резедә Мөхәммәтшина барлык катнашучыларны сәламләде һәм конференцияне ачык дип белдерде: «Татьяна Геллерның студенты булуым белән чиксез горурланам. Әни, әби булгач, аның хезмәтенең ни дәрәҗәдә югары булуын аңладым. Түгәрәкнең бер генә тапкыр булса да узмый калганын хәтерләмим, чөнки эш аның өчен һәрвакыт беренче урында иде. Конференциянең студентлар бәйрәмендә уздырылуы очраклы түгел. Татьяна Александровна студентларын гаиләсенә караганда да ныграк ярата иде».


Бүген конференция үз эшен 37 нче номерлы гимназиядә дәвам итә. Биредә «түгәрәк өстәл»ләр, ачык дәресләр узачак. Беренче көнне теориядә күрсәтелгән проблемалар гамәлдә тормышка ашырылды. Быел аның географиясе тагын да киңәйгән: Татарстаннан тыш, Түбән Новгород, Барнаул, Мәскәү, Ульян шәһәрләреннән, Казакъстаннан катнашучылар бар.

## Бездә кунак бар

# Роберт Пшель: «Безне уртак эшләр көтә»

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

24 гыйнвар көнне университетка НАТОның Мәскәүдәге Мәгълүмати бюросы директоры Роберт Пшель килде. Ул уку йорты җитәкчелегеннән тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов, инновацион эшчәнлек буенча проректор Наил Кашапов, тышкы элемтәләр департаменты җитәкчесе Андрей Крылов һәм әйдәп баручы галимнәр белән очрашты.





Алия Галимуллина фотолары

Линар Латыйповның сәламләү сүзләреннән соң, Роберт Пшель НАТОның Мәскәүдәге Мәгълүмати бюросы хакында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, бюро эшчәнлеге Россиянең киң җәмәгатьчелегенә РФ һәм НАТО арасындагы мөнәсәбәтләрнең ни рәвешле үстерелүен төшендерүдән гыйбарәт. Шул ук вакытта НАТОның нинди роль уйнавы һәм функция башкаруы турында Россия күләмендә мәгълүмат тарату буенча координацион пункт булып тора. Ләкин Казан галимнәрен бюро эшчәнлегенең икенче ягы кызыксындырды: фән эшлекләренә, төбәк, милли һәм халыкара дәрәҗәдәге семинарларны, конференция һәм «түгәрәк өстәл»ләрне дә кертеп, финанс ярдәме күрсәтү. Соңрак билгеле булганча, кунак белән очрашуга НАТО гранты ияләре – генетика кафедрасы доценты Альберт Ризванов һәм микробиология кафедрасы мөдире Ольга Ильинская да килгән иде.

Очрашуда НАТОның грант программалары тематикасы турында фикер алышу да булды. Казан галимнәре фикеренчә, тематика шактый тар һәм фән эшлекләләренең катнашу мөмкинлекләрен чикли. Ольга Ильинская, бу мәсьәләне хәл итү максатыннан, НАТОның грантлар белән эшләү бүлеге хезмәткәрләренең КФУга килүен оештырырга кирәк, дигән тәкъдим белән чыкты. Университетыбыз вәкилләре шулай ук студентлар өчен видеоэлемтәләр һәм онлайн-лекцияләр уздыру мөмкинлегенә бәйле сорауларны да күтәрде.

Шуннан соң Роберт Пшель Университет тарихы музеенда булды, «Россия һәм НАТО арасындагы мөнәсәбәтләр» темасына лекция укыды. Аны тыңларга Казан университеты мөгаллимнәре, аспирантлары һәм студентлары килгән иде. Роберт Пшель НАТОның тулаем эшчәнлеге, аның Россия белән хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре турында сөйләде. Алар арасында аеруча да игътибарга лаек булганнары террорчылыкка каршы көрәш, оборона реформасы, хәрби хезмәттәшлек һ.б. иде. Теманың актуальлеге, әлбәттә, тыңлаучыларның лекторга бик күп сораулар яудыруына сәбәп булды, шуңа күрә очрашуның икенче өлеше Роберт Пшель белән турыдан-туры әңгәмә, фикер алышу рәвешендә үтте.

Нәтиҗәләр ясап, журналистлар белән сөйләшкәндә, Роберт Пшель үзен җылы кабул иткәннәре һәм кызыклы фикер алышулар өчен рәхмәтен белдерде. «Казан университеты белән уртак эшчәнлекне оештырып җибәрә алачагыбызга ышанам. Димәк, безне уртак эшләр көтә», – дип белдерде ул.

# «Сезнең язмыш - сезнең кулларда!»

**Башы 1нче биттә.**

Залга җыелган һәр студентның максатчан, тырыш, актив булуы күренеп тора. Президент һәм башка мәртәбәле шәхесләр алдында да алар үз фикерен төгәл һәм ачык итеп җиткерә белә. Әлмәт дәүләт нефть институтыннан килгән студент Дамир Шәйхетдинов уку йортының фәнни эшчәнлеге белән таныштырды. Аның фикеренчә, фәнни үзәкләр күбрәк булырга тиеш. Залда бер ел элек кенә оешкан, ләкин зур уңышларга ирешкән «Лидер» яшьләр клубы вәкилләре шактый иде. Ул республикабызның иң актив яшьләрен берләштерә, яңа проектларын тормышка ашырырга ярдәм итә. Рөстәм Миннеханов тиз арада әлеге клуб вәкилләре белән очрашырга сүз бирде. Филология һәм сәнгать институты студенты Айгөл Батырханованы милләт язмышы, татар теленең киләчәге борчый. Үз чыгышында ул «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе эшчәнлегенә басым ясады. Әлеге оешманың татар халкын саклап калу, бөтен дөньяга сибелеп яшәүче милләттәшләребезне берләштерү өчен зур эш алып баруын әйтте. «Татар каналының тәүлек буенча эшләвен, безне сөендереп торуын теләр идек. Без дә яңа проектлар, кызыклы тапшырулар тәкъдим итә алабыз. Алар телебезне сакларга гына түгел, хәтта башка милләт кешеләренә татар телен өйрәнергә ярдәм итәр иде. Уку йортыбызның «UNIVER ТВ» каналында да татарча тапшырулар ачылыр дип ышанабыз», – диде Айгөл.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты студенты Степан Новиков үз чыгышында шулай ук бүгенге көндәге иң зур проблемаларның берсен күтәрде. Ул шәһәрнең архитектур төзелешеннән канәгать түгел. Бу уңайдан әлеге уку йортында зур эшләр алып барыла, төрле конференцияләр, «түгәрәк өстәл»ләр оештырыла. «Тарих бер көндә генә төзелмәгән, җимереп ату бик җиңел. Без аны сакларга тиеш. Тарихи үзәкне аеруча тәртипкә саласы бар», – дип үз тәкъдимнәрен җиткерде. Президентыбыз, яшь архитекторның фикерләрен хуплап: «Безгә, әлбәттә, сезнең ярдәм кирәк. Бу эш белән сезнең уку йорты гына түгел, ә калганнар да, барыбыз да шөгыльләнергә тиеш», – диде.

Чыгышлардан соң Рөстәм Миннеханов студентларны борчыган сорауларга да җавап бирергә өлгерде. Түбән Кама педагогия көллияте студенты фикеренчә, конкурс-фестивальләр бик күп, ләкин алар арасында фәнни фильм конкурсы да оештырылса, бик яхшы булыр иде. Шулай ук мәктәпләрдә сәламәтлек дәресләрен кертергә кирәк. «Проблеманы тулысынча хәл итмәсә дә, алкоголь куллану, тәмәке тартуны ачыклый торган тикшеренүләр үткәрү дә нәтиҗәсез калмас иде», – диде студент яшьтәшләре өчен кайгырып. Яшь буынны тагын эшсезлек, IX сыйныфтан соң һөнәри уку йортына укырга керү, җәмгыятьтә укытучының роле, үз хокукларыңны яклый белү кебек проблемалар борчый. Президент, һәр чыгышны тыңлап, сорауларга җавап биреп барды. Йомгаклап: «Сез без тормышка ашырырга теләгән максатлар белән яшисез, проблемалар уртак икән. Ешрак очрашырга, аралашырга кирәк. Чакырыгыз гына, без килергә, ярдәм итәргә һәрчак әзер. Шуңа басым ясыйсым килә: сез безгә караганда белемлерәк, активрак. Сезнең язмыш – сезнең кулларда. Уңышлар!» – диде.

Дөрестән дә, җитәкчеләребезнең яшьләр белән очрашуы, үз нәтиҗәсен бирми калмас. Студентлар күрсәткән проблемалар уңай якка чишелер, ә яшь буын өчен тудырылган шартлар, мөмкинлекләр дөрес файдаланылыр, дип уйлыйм.

***Андрей Фурсенко,** РФның мәгариф һәм фән министры: «Татарстан – Россиянең иң алга киткән республикаларының берсе. Биредә студентлар өчен бөтен шартлар да тудырылган. Актив булыгыз, Татарстан Россиянең генә түгел, бөтен илнең алдынгы төбәгенә әйләнер».*

***

***Виктор Садовничий,** МДУ ректоры: «Татьяна көне – бөтен Россия студентлары, Мәскәү дәүләт университетының туган көне. Без КФУга бу бәйрәмне зурлап үткәрүе өчен рәхмәтле. Сезнең белән дустанә мөнәсәбәттә яшәвебез, хезмәттәшлек итүебез гомерлек булсын. Яңа үрләр сезгә!».*

***

***Олег Морозов,** РФ Дәүләт Думасы рәисенең беренче урынбасары, КДУның элекке студенты: «Сезне иң яраткан бәйрәмнәремнең берсе белән тәбрик итәм! Студент елларын бик мәгънәле итеп үткәрергә кирәк. Бу киләчәккә төп адымны ясау чоры. Гашыйк булып, күңел ачуга гына кайтып калмасын иде. Вакытны файдалы үткәрегез!»*

● Галимнәребез

# «Йөк ташучы, татарин…»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Гыйлем (Гыйльметдин) Хәйретдин улы Камаев 1901 елның 23 февралендә туа. 9 яшеннән ятим калып, башта ат белән йөк ташучы, ә 14 яшеннән йөкче булып эшли башлый. Укырга йөк ташучылардан, пароходларның исемнәре буенча өйрәнә.

1917 еллардагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә, Татар мөгаллимнәр семинариясе ачыла. Г.Камай бар булганын белем алуга, яшьләр белән эшләүгә багышлый. Комсомолга керә, сәясәт белән кызыксына башлый. Ш.Усманов тәкъдиме белән Мәскәүгә, аннары Перекопка татар-башкорт гаскәрләрен агарту эшенә җибәрелә. Врангельне җиңгәч, 1921 елда демобилизацияләнә. 1922 елда Томск университетына укырга җибәрелә. Эш сөючән Гыйлем тик тормый, югарырак курсларда балалар йорты мөдире булып эшли, Себер төрки-татар педагогия техникумында укыта.

Г.Камайның диплом эше бензол кушылмаларны нитролау тизлеген өйрәнүгә багышланган була. Җитәкчесе аны аспирантурага калырга өнди. Г.Камай истәлекләреннән билгеле булганча, бер галим, моны ишеткәч, университетның Гыйльми советында: «Сез нәрсә, кемне кафедрада калдырмакчы буласыз? Ул бит грузчик, татарин, җитмәсә, коммунист», – ди. Җитәкчесе Камайны яклап чыга, ләкин язмыш аны Казан университетына юнәлтә.

Казан университетында ул тулысынча химия дөньясына чума. А.Е.Арбузов кулы астында фосфор химиясен өйрәнә. Г.Камайны биредә җылы каршы алмыйлар, ләкин максатчанлыгы аркасында теләгенә ирешә. Бу турыда үзе: «Мин А.Е.Арбузовның икенче аспиранты булып киттем. Без аның олы улы Борис белән 9 га эшкә килә һәм кичке 11 ләрдә генә кайтып китәидек. А.Е.Арбузов миңа беркайчан да кисәтүләр ясамады, түземлек белән генә төзәтеп җибәрә иде. Ә Бориска карата бик таләпчән булды. Ул беркайчан да атасына каршы сүз әйтми, тыңлый һәм аның кушканнарын эшли иде», – дип яза.

А.Е.Арбузов Г.Камай турында: «Тиофосфин кислоталарының әлегә билгесез кушымчаларын табу Г.Камайдан бик зур көч һәм түземлек сорады. Торбалар шартлап, берничә атна буена тырышкан хезмәтләр юкка чыгуга карамастан, яшь аспирант кат-кат яңабаштан башлангыч кушымчалар әзерләргә тотына иде. Г.Камай тиздән яңа фосфор кушылмаларын табу мәсьәләсенә ачыклык кертер», – дип язып калдырган.

Аспирантураны тәмамлаганнан соң, Г.Камай Германиягә белем күтәрергә җибәрелә. Тюбинген университетында Я.Мейзенгеймер кулы астында мышьяклы органик кушылмалар синтезлау өстендә ел ярым эш алып бара. Германиядәге эшен йомгаклап, немец телендә чыгыш ясавы һәм тикшеренү нәтиҗәләре белән таныштыруы немец коллегаларын шаккатыра. Ул вакытларда сирәк була торган күренеш – Г.Камайны немец химиклар җәмгыятенең мактаулы әгъзасы итеп сайлау – галимнең таланты һәм уңышлары турында сөйли торган бер факт.

1931 елда Германиядән кайткач, арадаш продуктлар һәм буяучы матдәләр кафедрасы мөдире, ә берничә айдан (30 яшендә) КДУ һәм КХТИ профессоры итеп сайлана.



■ Гыйлем Камай тормыш иптәше Рәйсә, кызы Светлана һәм улы Руслан белән

1935 елда Г.Камай КДУ ректоры итеп билгеләнә. Бу Казан дәүләт университеты тарихында татарны шундый баскычка күтәргән беренче факт була. Ул ректор булган чорда химия факультеты һәм ике тулай торак бинасы салына башлый. Әмма 30-40 нчы еллардагы террор Г.Камайга тими калмый. Ул 1937 елда репрессияләнә, ректорлыктан төшерелеп, төрмәгә эләгә.

Дәһшәтле сугыш яңа технологияләр, шартлаткыч матдәләр әзерләүне таләп итә. Бу исә галимнәрне барлауны сорый. 1939 елның маенда Г.Камай ирекккә чыгарыла. 1941 елда докторлык диссертациясе яклый. Сугыш елларында нитрокушылмалар (шартлаткыч матдәләр) химиясе һәм технологиясе өстендә эзләнүләр алып бара. Оригинал хезмәтләре өчен 1952 елда Г.Камайга Сталин премиясе бирелә.

Г.Камай 1970 елның 17 мартында кинәт кенә вафат була. Химия өлкәсендәге уңышлары һәм фәнни хезмәтләрен бәяләп, ике мәртәбә Ленин, өч мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, СССР медальләре белән бүләкләнә. Ул – Дәүләт премиясе лауреаты, 1961 елдан РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе. Казан урамнарының берсе аның исемен йөртә. Татарстан Фәннәр академиясе Г.Камай исемендәге премия дә булдырды.

***(«Мәшһүр татар галимнәре» китабы файдаланылды).***

● Кечкенә галимнәр

# Көянтә

**Рифә РАХМАН**

**(Дәвамы. Башы 1 (14) санда)**

Сусылуның башына бер уй керсә, тиз генә куып чыгарам димә. Бу юлы да шулай булды. Массажистка барганда да, аңа чират көткәндә дә, гел көянтә турында гына уйлады.

Сусылуның әтисе елын-елына елкы-сыер ише мал симертеп суя торган иде. Башта агартканчы бакча карында тибәрләр дә, аннан мөлдерәмә потлы чиләкләрне көянтәгә асып, Ерак чишмәгә чайкарга китәрләр. Анда да халык тулы. Инеш бозында эчәге тибүчеләре дә, улакларда чистага чайкаучылары да җитәрлек. Иң беренче тапкыр эчәге типкәндә, аңа нибарысы яшьтән артык кына иде әле. Ул моны бик яхшы хәтерли, чөнки көзге яңгырлы көннәрнең берендә бабасы нәкъ төн уртасында ишегалды ягындагы тәрәзәләрен шакыды. Вакытын соңрак шуннан белде: авыл электр станциясе нәкъ менә шул вакытта ток бирүдән туктый икән, ә аларның, ут сүнгәч, ятып йокларга азапланып маташкан бер мәлләре иде.

Тавышны иң элек әнисе ишетте. Җиделе лампаны яндырып, аш бүлмәсеннән язу-сызуныкына чыкты, Сусылу курыкмасын дип, азрак яктылысын – бишлесен, өстәл өстенә кабызып калдырды. Алар бу сүрән яктылы лампаны ашаганда яндыралар, ә көчлерәк утлысының кәрәчинен әнисе дәфтәр тикшергәнгә дип саклый иде. Ул пыяла куыкларны һәр көнне сөртеп ялтыратып куя, сүндерүгә, бүлмәгә исе тарала, башны авырттыра дип, чоланга чыгара.



■ Кечкенә Рифә әти-әнисе белән

Бабасының озын буена да, аны бик яратуына да иң элек шул көнне игътибар итте Сусылу. Еракта яшәгән авылларыннан, эш вакыты дип тормыйча, туган көне белән котларга килгән иде ул аны. Димәк, 16 сентябрь булган. Ул аның күңеленә, лампадан төшкән күләгәсе белән бергә кушылып, озын бер кеше булып кереп калган иде, җәен кунакка баргач, күпкә кыскарак буйлы икәнлеген күреп шаккатты, әмма барыбер бөтен бабайлардан озын, шаян, матур иде ул Өскекүлдә!

Бабасы аны туганнарыннан иң беренче булып туган көне белән котлаучы да булып чыкты. Күксел фирүзә төсендәге, җиләк ашаучы ак кош рәсемле көянтә алып килгән иде ул теге төндә. Көянтәгә, бабасының теләкләренә Сусылудан да битәр әнисе сөенде.

– Кызың игелекле, тырыш булып үссен, сине ярдәменнән калдырмасын, – дигән иде ул аңа. – Хезмәт сөйгән кешенең бозыларга вакыты булмый.

Сусылу көянтәне, юка җиңел агачтан эшләнгән һәм бик тә, бик тә кечкенә булса да, көчкә-көчкә генә күтәрде. Үзе дә көянтә биеклегендә генә иде әле.

– Ничава, җәйгә үсәрсең, әбиең белән безгә дә су ташырлык булырсың, – диде бабасы. – Өскекүлдә Матур апаңнан калганы бар. Анысы да бик җиңел, төсе генә яшел. Аның каравы алмалар, чәчәкләр ясалган аңа. Моннан бераз зуррактыр. Мондый бәләкәй көянтәне ясамыйлар да икән. Останы көчкә тыңлаттым. Безнең нәсел тууга эшли башлый ул, дидем. Син, кызым, безне дә уздырырга охшаган. Үзеңә бер яшь кенә, әнә ничек шәп сөйләшәсең.

Аңа кадәр дә Сусылуның бабасын, бәлки, әллә ничә күргәне булгандыр, әмма ул аны нәкъ менә шул көннән, көянтә китергән көннән хәтерли. Бабаларына кунакка баргач, аны кысла-аккош-чуртан рәсемле чиләкләр аскан көянтә күтәртеп рәсемгә төшергән Гәрәй абыйсын җәен дә күргәне бар сыман, ә менә бабасын шул көннән генә бик нык исендә калдырды. Ерак бабасының уйнап торган шук күзләрен дә, шүрәленеке кебек озын бармакларын да, какча озын гәүдәсен дә, көлке сөйләргә яраткан, гел көлеп торган иреннәрен дә. Әбисен әнә кыш-яз узгач килгән җәйдән, яңа йорт болдырындагы кадакларга эленгән көянтәләрне сайлашкан вакытыннан гына яхшы хәтерли.

Кара, барысы да шул көянтәгә барып тоташа. Өченче бик матур көянтәсен инде аңа әнисе Алгай кешесеннән бөтен теләкләрен искә алып ясатып бирде, җилкә турысына алмалар, чияләр төшерттерде, чиләк элгечләрен тагын да шомартты, агачның да җиңелен, бик юкасын сайлатты, ә менә төсне үзгәртмәде: бабасының бүләген хәтерләтсен дип, Сусылуга да ошаган күксел фирүзәгә буятты. Әнисе үзенә ясатканыннан күпкә матуррак иде бу көянтә, шуны авылдашларыңа күрсәтер өчен генә дә суны ташырсың да ташырсың.

Су дигәннән, бабаларының чишмәсе дә якын булып чыкмады. Урам аркылы чыгасы, түбән урамны узасы, тыкрыктан төшәсе, тау баскычларын санъйсы, инеш ташларын шомартасы, тагын бераз гына сукмактан атлыйсы да... Инде секунды-минуты белән чиләгеңне тутырачак улакка килеп тә җиткән буласың. Бу суны Әхтәм чишмәсенекеннән кайтыш дисәләр дә, ярата иде Сусылу, чөнки тәме белән Бөр буендагы чишмәләр суын хәтерләтә.

Түбән урамда Сусылуның Сөннәтче әбисе яши икән. Ул аны Ерак әбиләренә якын торганга, Якын әби дип атый. Самавыр торбасындагы күркә җылысында гына чәй кайнатып эчкән әбкәсенә дә алып кергәли иде ул суны, чөнки аның җемелдәп көлгәнен, яратып аркасыннан сыйпаганын күрәсе, тоясы килә.

Көянтә дигәннән, аны күрше кызына сорап кергәннәрен белгәч, йөрәге ярылгандай булды Сусылуның. Инде Лаеш техникумында укыса да, балачагын тартып алалар сыман тоелды. Әнисенең чиннек такталарындагы кадакка эленгән кечкенә көянтәгә үзенең дә уйланыбрак үрелгәнен күрде дә, күзеннән тып итеп яшь тамды.

– Кызым, күршеләргә ничек каршы киләсең, үпкәләрләр шикелле, кызлары үскәч, кайтармасалар, кире сатып алырбыз, – диде ул.

Сусылу дәшмәде. Өйдә олыларга кире әйтү гадәте булмаганга, тешен кысып түзде, очраса, шундый ук көянтәне эшли башлауга үзе сатып алырга уена беркетте, туйганчы бер елар өчен, лапас артына чыгып басты.

***(Ахыры киләсе санда).***

• Тәүге адымнар

# Булачак укытучы көндәлегеннән...

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче



***12.01.12***

Кызык саннар җыелмасы... Менә бүген мин беренче тапкыр мәктәпкә бардым. 13 нче гимназия безне, 4 студент һәм әдәбияттан методистыбыз Рамил абыйны, җылы каршы алды. Бусагасын атлап керүгә үк, «Исәнмесез», дип берәү исәнләште. Тавыш килгән якка борылып карасам, кечкенә генә кыз урындыкка утырган да аяк киемен киеп маташа.

Гимназиянең директоры, татар теле һәм әдәбияты укытучысы белән таныштык... «Эшләргә була!» – дигән фикергә килдем. Укучылары тәрбияле, тәртипле; гимназия күңелемә хуш килде. Шул транспортта йөрү генә бераз кәефне төшерде, 1300 сумлык стипендия тулысы белән юлга гына чыгып очачак икән... Ярар, хәерле булсын.

***19.01.12***

Вакытның үткәне сизелми дә диярлек. Менә бер атна үтеп тә киткән. Мин бүген беренче тапкыр дәрес бирдем. V сыйныфларда – әдәбият һәм өченчеләрдә – уку. Бигрәк тә III сыйныфлар ошады, үзләре әле сабыйлар, матурлар, игътибарсызлар... Күзләрен тутырып авызга гына карап торалар. Дәресемне бик ошаттылар, дәрес бетәргә бер 10 минут кала, уеннар уйнаткан идем, шул бик ошады. Тагын керегез инде, дип калдылар. Эх, шундый балаларны укытыр идем мин, әлбәттә.

***21.01.12***

Көн бик салкын... Бүген миңа беренче дәрескә иде. Укытучыбыз җитди сәбәпләр аркасында мәктәпкә килә алмады, шуңа күрә мин укытам. Башта тугызларда иде дәрес. Хет кычкырып ела инде, сине бу сыйныфта кешегә дә санаучы юк. Әлеге гимназиядә дә шундый сыйныф бар икән! Һәркем үз эше белән мәшгуль, кемдер рус әдәбиятыннан әсәр укып утыра, кемдер телефонында казына, кемдер музыка тыңлый, гомумән, татар теле дәресендә гамьнәре юк. Акырып, кычкырып, үземнең генә башым авыртачак.

Икенче дәресем – өчләрдә татар теле. Менә, ичмасам, ял итеп чыгарга була... Аларда дәрес бирәм дә бер көн ял аннары.

***23.01.12***

Бүген мин мәктәпкә бераз соңарып бардым, дәресләргә кермәдем. Сигезләрдә сыйныф сәгате үткәрдем. Темасы – «Ленинград блокадасы» иде. Теманы юктан гына сайламадым, чөнки 27 гыйнвар көнне Ленинград блокадасы тулысы белән өзелә. Укучыларга кызыграк булсын дип, презентация дә, документаль фильмнардан өзекләр дә алып килгән идем. Теманы уңышлы гына аңлаттым дип уйлыйм. Алып килгән фильм белән кызыксынучы укучыларым да булды, үзләренә дә алып калдылар. Башка яңалыклар юк, атнаны хәерле генә башлап җибәрдек!

• Тәңгә – мунча, җанга – юк

# Баш авырта шул...

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Дискотекаларга йөрергә яратмыйм мин... Нәрсә бирә ул? Ял итеп кайтырга дисезме? Ялны кем ничек күз алдына китерә инде...



Шулай да беркөнне азрак гадәти көнкүрешне алыштырып кайтыйк әле дип, дуслар белән дискотекага киттек. Дөресрәге, дискәтүккә. Хәзер яшьләр арасында шул сүз популяр. Социаль челтәрләрдә гел реклама ясап торалар. Җаның кайда, нинди дискотекага тели, шунда бара аласың. Ни генә тәкъдим итмиләр бит анда?! Дәртле музыка! Иң шәп диджейлар! Иң оста телле алып баручылар! Без татар дискәтүкләрен күреп кайтырга булдык... Рәхәтләнеп татар җырларына биеп, уеннарда катнашып, иң мөһиме, тәмәкесез, исерекләрсез урында ял итәсебез килде...

Төнге клубларның берсендә безне баһадир гәүдәле сакчылар каршы алды. Фейс-контроль дигән әйбер юк икән монда. Димәк, Колхоз базарыннан алган иң арзан кием белән дә үтеп була. Сөенеп куйдым: безнең кебек авылдан килгән кызлар-егетләр ял итәдер әле, гел монда килергә кирәк...

Урамнан ук ишетелеп торган көчле музыка, бина эченә кергәч, баш миенә бәрә башлады. Безнең колаклар тыныч кына сөйләшкәнгә, моңлы көйләргә ияләшкән шул... Ярар, дискәтүк булгач, дискәтүк булсын инде... Без нигә әле урыслардан ким булырга тиеш, ди?!

Арттырып җибәрәбез, җәмәгать... Үзләренчә «купшы» итеп киенгән татар яшьләре бер дә мин күз алдына китергәнчә ял итми икән шул... Күренеп тора: авылдан килгән егетләр-кызлар, килеп җитмәс борын, бар өстәлләренә таба ашыга. Горур гына барып сыра алдылар да күңел ачучылар арасына кереп югалдылар. Ә алар янына бара торган түгел. Әллә нинди аңлашылып бетми торган көйләргә төрле хәрәкәтләр ясый-ясый бииләр. Менә татар дискәтүге диген син, ә?! Әле ике көн элек кенә хит булган җырга ремикс ясалган иде. Ә монда шул ремикска мегаремикс уйный. Татар милләте артта калган халык, дип әйтергә ничек тел әйләнсен, ди?! Безнең ремикс ясарлык җырлар беткәнмени?

Бер мәлне бөтен яшьләр бертавыштан кычкыра-кычкыра кул чабарга тотынды. Ни күзем белән күрим, сәхнәбез түренә ярымшәрә ике кыз чыгып басты!!! Алар «Go-Go» бии икән... Бу эротик биюнең бер стиле, бары тик биючеләр чишенми. 1960 елларда Нью-Йорк шәһәрендә барлыкка килгән бию безнең якларга да килеп җитте. Бөтен егетләрнең күзләре шул кызларда. Бер туташ матур гына бии торган җиреннән туктады да янында басып торучы егеткә менеп төште. Тегесе сәхнәдәге хур фәрештәләреннән күзен ала алмый тора бит... Эх, минәйтәм, шунда милли киемнәребездән чыгып, яшьләрне өздереп бер татарча биетәсе иде дә бит... Кая инде, ничек заманадан артта каласың, ди?! Рәхәтләнеп биесеннәр!!!

Күзне төтен кисә генә бит. Әллә телевизордагы кебек төтен чыгарталар микән? Булган, ди! Паровоз урынына егетләр тәмәке тарта. Болай да кысан бинада бөтенләй һава юк. Егетләр генә булса, ачуым килмәс иде, кызлар арттырып та җибәрә! Менә авылның үрнәк кызлары шәһәрдә ничек ял итә! Нишләп әле шәһәрдә генә? Авылда да шул хәл бит... Алар кайталар да үзләрен бары тик «яхшы» яктан гына күрсәтеп, иптәшләрен өйрәтәләр. Имеш, сез модадан артта каласыз, ял итә белмисез! Менә ата-ана биргән акчаны кайда туздыра балачага... Керү бәясе дә 200 сумнан ким түгел, газлы су гына эчим дисәң дә, 50-100 сум акчаңны чыгарып салырга кирәк. Ә мескен ата-ана авылда тир түгә, баласын Кеше итү өчен тырыша.

Мине яшь буын бик аңлап та бетермәс, сине анда барырга кем мәҗбүр итә, дияр. Дөрес, күз күрмәгән, баш авыртмаган, диләрме әле?! Баш авырта шул... Бары тик рәхәтләнеп, татар дискәтүгендә ял итәсем килә иде минем... Мин безнең өчен борчылмыйм... ә бездән соң киләчәк буын өчен борчылам...

• Дөнья үзебезнеке

# Кем соң мин?



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

*Нью-Йорк шәһәренең бер урта мәктәбендә эшләүче укытучы үзенең чыгарылыш сыйныф укучыларының,башкалардан кайсы яклары белән аерылып торуларын күрсәтеп, күңелләрен күтәрергә була. Калифорния штатыннан галим Хелис Бриджес тәкъдим иткән методны кулланып,ул һәр укучыны такта янына чакыра,аның үзенең һәм сыйныф тормышында тоткан урынын әйтә. Аннан соң укучыларына алтын хәрефләр белән «Кем соң мин?» дип язылган зәңгәр тасма бүләк итә.*

*Укытучы моның белән генә тукталып калмый. Ул кайсы да булса кешенең казанышларын тану җәмгыятьтә нинди роль уйнаганын тикшереп карарга була. Укучыларына тагын шундый ук өчәр тасма бирә һәм үзләре белән үткәрелгән церемонияне мәктәптән тыш уздырырга тәкъдим итә. Нәтиҗәне бер атнадан ясарга дип килешәләр.*

*Бер укучы үзе яши торган йорт янындагы фирманың офисына юнәлә. Анда аңа киләчәктә үз карьерасын планлаштыруда кече хезмәткәр ярдәм иткән була. Укучы малай бу әфәндегә аның кылган яхшылыгын әйтә һәм түшенә зәңгәр тасманы эләктереп куярга рөхсәт сорый. Калган икесен кулына биреп:*

*— Без сыйныфта эксперимент үткәрәбез. Үзегез лаек дип санаган берәр кешене табып, бер тасманы аңа бүләк итегезче. Ә ул,үзе теләгән икенче бер кешегә тапшырып,церемонияне шулай ук дәвам итсә иде. Ахырдан, минем белән элемтәгә кереп,нәтиҗәләрне әйтәсегез генә кала,— ди.*

*Шул ук көнне бу хезмәткәр үзенең холыксыз җитәкчесенә керә. Ул аның утыруын үтенә. Кече хезмәткәр ихластан җитәкчесенең эшлекле һәм булдыклылыгына соклануын әйтә. Җитәкче аптырап кала. Хезмәткәре аңа зәңгәр тасманы бүләк итеп,түшенә эләктереп куярга рөхсәт сорый. Тагын бер тасманы аңа биреп:*

*— Миңа бу тасмаларны биргән малай мәктәп проектында катнаша һәм без аны дәвам итәргә булдык. Үзең турында башкалар фикере, казанышларыңны тану язмышыңа тәэсир итәме? дигән сорауны ачыкларга телибез,— ди.*


*Кич белән өенә кайтуга,җитәкче үзе янына 14 яшьлек улын чакырып ала да аңа:*

*— Минем белән бүген шаккатмалы хәл булды... — дип,үзе белән булган хәлне сөйләп бирә. — Теге зәңгәр тасманы кемгә бирергә икән,дип уйлап кайтканда,син исемә төштең. Минем тормыш бик ыгы-зыгылы. Эштән кайткач,сиңа игътибарым да җитми. Кайчагында мәктәптә начар билге алганга,өйне җыештырмаганга ачуланам да. Ә бүген минем, синең янга утырып,тормышымда нинди зур урын тотканыңны әйтәсем килә. Әниеңнән соң син минем тормышымда иң әһәмиятле кеше. Син менә дигән егет һәм мин сине бик яратам!*

*Аптыраган малайның гәүдәсе калтыранырга тотына һәм ул тыела алмыйча елый башлый. Аннан соң ул әтисенең күзләренә күтәрелеп карый һәм яшь аша:*

*— Иртәгә иртән мин үз-үземә кул салмакчы идем,әти. Син мине бер дә яратмыйсың, минем берәүгә дә кирәгем юк кебек тоелган иде. Хәзер кире уйладым... — дип җавап кайтара.*

*(Хелис Бриджес)*



DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева, Э.Р.Ибраһимова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-40-10, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла